КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 сентябрь г.Казань № 877

Җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яки әйләнә-тирәдәге шартларда ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативын раслау турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яисә тирә-юньдә ориентлашу сәләтен югалткан затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2017 ел, 10 июль, ТРЗ-50 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә, 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына җирле үзидарә органнары тарафыннан җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яки әйләнә-тирәдәге шартларда ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләп чыгару максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яки әйләнә-тирәдәге шартларда ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

2021 елга – 1 койка-көнгә 613,53 сум;

2022 елга – 1 койка-көнгә 615,02 сум;

2023 елга – 1 койка-көнгә 616,55 сум.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яки әйләнә-тирәдәге шартларда ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативына инфраструктура белән тәэмин ителүдәге аермалыкларны һәм хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативы мәгънәсенә йогынты ясый торган башка факторларны исәпкә ала торган корректировкалау (төзәтү) коэффициентлары;

2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яки әйләнә-тирәдәге шартларда ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү буенча койкалар саны.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яки әйләнә-тирәдәге шартларда ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативын раслау турында» 2019 ел, 2 сентябрь, 751 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 28 сентябрь, 877 нче
карары белән расланды

2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яки әйләнә-тирәдәге шартларда ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативына инфраструктура белән тәэмин ителүдәге аермалыкларны һәм хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативы мәгънәсенә йогынты ясый торган башка факторларны исәпкә ала торган корректировкалау (төзәтү) коэффициентлары

| Муниципаль берәмлек исеме | Корректировкалау (төзәтү) коэффициенты күләме | | |
|---|---|---|---|
| | 2021 год | 2022 год | 2023 год |
| Азнакай муниципаль районы | 1,729984 | 1,730158 | 1,730397 |
| Әлмәт муниципаль районы | 1,729984 | 1,730158 | 1,730397 |
| Бөгелмә муниципаль районы | 1,729984 | 1,730158 | 1,730397 |
| Алабуга муниципаль районы | 1,729984 | 1,730158 | 1,730397 |
| Зәй муниципаль районы | 1,729984 | 1,730158 | 1,730397 |
| Зеленодольск муниципаль районы | 1,793439 | 1,793459 | 1,793541 |
| Лениногорск муниципаль районы | 1,729984 | 1,730158 | 1,730397 |
| Түбән Кама муниципаль районы | 1,729984 | 1,730158 | 1,730397 |
| Чистай муниципаль районы | 1,729984 | 1,730158 | 1,730397 |
| Яр Чаллы шәһәре | 1,080453 | 1,081198 | 1,081981 |
| Казан шәһәре | 1,080609 | 1,081354 | 1,082159 |

________________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 28 сентябрь, 877 нче
карары белән расланды

2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яки әйләнә-тирәдәге шартларда ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү буенча койкалар саны

| Муниципаль берәмлек исеме | Койкалар саны |
|---|---|
| Азнакай муниципаль районы | 10 |
| Әлмәт муниципаль районы | 10 |
| Бөгелмә муниципаль районы | 10 |
| Алабуга муниципаль районы | 10 |
| Зәй муниципаль районы | 10 |
| Зеленодольск муниципаль районы | 10 |
| Лениногорск муниципаль районы | 10 |
| Түбән Кама муниципаль районы | 10 |
| Чистай муниципаль районы | 10 |
| Яр Чаллы шәһәре | 20 |
| Казан шәһәре | 40 |